ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 15 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

2) 5 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системаларында катнашучыларның Татарстан Республикасы территориясендә үзара хезмәттәшлеге тәртибен Федераль законда билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында билгеләү (шул исәптән дәүләт юридик бюроларының әлеге түләүсез юридик ярдәм системаларында башка катнашучылары белән үзара хезмәттәшлеге өлешендә);»;

3) 9 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:
«$1^1$) Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил;»;

4) 10 статьяда:
а) исемендә «учреждениеләр,» сүзеннән соң «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил,» сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә үз компетенциясе чикләрендә булыша.»;

5) 12 статьяда:

а) 1 өлешнең $3^{2}$ пунктында «Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә» сүзләрен «Россия Федерациясе Кораллы көчләренә яисә Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) инвалидларга медик-социаль экспертиза үткәрү, аларны реабилитацияләү һәм инвалидларны абилитацияләү;»;

6) 17 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар ведомстволарындагы учреждениеләр, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары, дәүләт юридик бюросы» сүзләрен «әлеге Законның 9 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^{1}$ өлеш өстәргә:

«$1^{1}$. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар халыкка хокукый мәгълүмат җиткерүне һәм аны хокукый гыйлемле итүне Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 5 пунктының «б» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 5 пунктының «б» пунктчасы 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 01 март
№ 6-ТРЗ